Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Дуртмунчинского
сельского поселения Заинского
муниципального района

ул. Молодежная, д.148, с Дурт-Мунча,
Заинский район, (423515)
тел. 6-03-10

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Дүрт-Мунча авыл җирлеге
башкарма комиты

Яшьләр урамы, 148 нче йорт,
Дүрт-Мунча авылы, Зәй районы
(423515) тел. 6-03-10

Телефон, факс 60 3 10. Электронный адрес: Durt.Zai@tatar.ru, сайт: www. durtmuncha.ucoz.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**31.01.2025 ел** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставы, Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елның 1 февраленнән Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 9165 сум 37 тиен күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2024 елның 30 гыйнвардәге 3 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарның гамәлдә булуы рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый порталында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**Дүрт-Мунча авыл җирлеге** **Р.Т.Ситдиков**

Зәй муниципаль районы
Дүрт-Мунча авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2025 елның 31 гыйнварыннан
3 номерлы карарына
1 нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән
Дүрт-Мунча авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәтләр атамасы | Хезмәтләр бәясе (сумга) |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 486,04 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1 490,01 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 189,32 |
| Барысы | 9 165,37 |

Зәй муниципаль районы
Дүрт-Мунча авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2025 елның 31 гыйнварыннан
3 номерлы карарына
2 нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән
Дүрт-Мунча авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүү | 0,00 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 955,88 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 601,58 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1 454,39 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 4 153,52 |
| Барысы | 9 165,37 |